**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 ноябрь № 848

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 19 июнь, 416 нчы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 апрель, 237 нче, 2015 ел, 15 апрель, 255 нче, 2015 ел, 18 май, 354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Тапшырыла торган барлык документлар анык бастырылган һәм барлык пунктлар буенча да тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта сызык куела). Бозулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, мөһер белән таныкланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) һәм вәкаләтле зат мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) яки үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш.

Конкурс заявкасының барлык битләренә сан сугылган булырга тиеш. Документлар күчермәләре раслауга вәкаләтле зат имзасы һәм эшкуарлык субъекты

мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш. Конкурс заявкасы тегелгән һәм раслауга вәкаләтле зат имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере белән расланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) яки үз кулы белән расланган (шәхси эшмәкәрләр өчен), конкурс заявкасының икенче ягында битләрнең гомуми саны күрсәтелгән булырга тиеш.»;

4.1 пунктта:

икенче абзацта «(юридик затлар өчен)» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле зат имзасы һәм гариза бирүче мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда), конкурс заявкасын бирү вакытына хезмәткәрләрнең эш хакы күрсәтелгән гариза бирүченең штат җәдвалы яисә вәкаләтле зат имзасы һәм гариза бирүче мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда), конкурс заявкасын бирү вакытына хезмәткәрләрнең эш хакы күрсәтелгән эшмәкәрлек субъекты хезмәткәрләре саны турында мәгълүмат булган бүтән документ;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«узган календарь елына хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны турында мәгълүматлар;»;

алтынчы абзацны җиденче  абзац дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит телдәге документларны гариза бирүче аларның билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемәләре белән бергә тапшыра.»;

7.5 пунктта:

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) гамәлдәге эшмәкәрлек субъектларына – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыклары белән расланган «2014 елда Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» һәм «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» ведомство программалары буенча конкурс сайлап алуы җиңүчеләренә тиешле финанс елына лизинг шартнамәсе буенча аванс түләвен түләүгә гамәлдә тотылган чыгымнарны каплауга лизинг шартнамәсе суммасының 70 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 3 млн.сумнан артык түгел;»;

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыклары белән расланган «2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында эшли башлаучы фермерларга булышлык күрсәтү» ведомство программасы буенча конкурс сайлап алуы җиңүчеләренә тиешле финанс елына җиһаз лизингы

шартнамәсен төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә максатчан чыгымнарны өлешле финанслау шартларында лизинг шартнамәсе суммасының 70 проценты күләмендә, әмма бер алучыга 1 млн.сумнан артык түгел;»;

«ж» һәм «з» пунктчаларында:

«режимлы объектларның җитештерү мәйданнарында» сүзләренә кадәр «Җәзалар үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең» сүзләрен өстәргә;

«эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтүнең инновацион инфраструктурасы объектлары хезмәтләреннән файдаланучыларга» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төзелгән төбәк инжиниринг үзәкләре хезмәтләреннән файдаланучыларга» сүзләренә алмаштырырга»;».

2. Бу карарның көче 2015 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\848.docx